Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2022 елның 14 ноябре № 3

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мамашир авыл җирлегенең Тәмәй авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында 2022 елның 25 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Авыл мәчете бинасында халык җыены үткәрү.Тәмәй авылы, Ленин ур., 2А.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: " Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегэ , 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган куп балалы гаилэлэрдэн,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәкләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2023 елда һәр бәлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- Тәмәй авылындагы урам - юл челтәрен төзекләндерү,ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

- тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру , Тәмәй авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

" ӘЙЕ " « КАРШЫ"»

3.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

4. Халык җыенын Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамаширавыл җирлеге башлыгы И.Г Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702